**СОВЕТ**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2023 Кодаш авылы № 26-1

Адреслашу объектларына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр һәм торак пункт чикләрендәге планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, адресларны һәм исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыруны Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. Адреслашу объектларына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр һәм торак пункт чикләрендәге планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, адресларны һәм исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыруны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшырырга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карар нигезендә Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында килешү төзергә тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карар буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында килешү рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге Советы рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М,ШАКИРОВ